**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Чирмешән авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

**03 декабрь 2025 ел** **№ 9**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлегенең
Казанка торак пунктында 2026 елда
гражданнарның үзара салымын кертү
һәм аннан файдалану турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге составына керүче Казанка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елда Чирмешән авыл җирлегенең Казанка торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, сугышчы-интернационалистларның тол хатыннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, «Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йорт» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә яшәүче гражданнардан, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- **коймаларны ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (Казанка торак пунктындагы зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту, дератизация чараларына түләү, корыган агачларны һәм куакларны кисү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);
- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау**

(монтажлау, демонтажлау, ремонтлау, яктырткычларны алмаштыру, Казанка торак пунктында, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Казанка торак пунктындагы чишмәләр территорияләренең санитария-яклау зоналарын төзекләндерү һәм карап тоту, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);
- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү, Казанка торак пунктында урамнарны карап тоту, үлән чабу, ботакларны, агачларны, төзелеш чүп-чарларын җыю, триммерлар сатып алу, тракторны карап тоту, аңа хезмәт күрсәтү чыгымнары, тракторчыга хезмәт хакы, ягулык-майлау материаллары сатып алу, арба һәм махсус техника сатып алу, запас частьләр, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материалларны сатып алу, йортларга адреслы табличкалар сатып алу).

2. Бу карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Д.Г.Долгополов